**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 ноябрь № 905

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру чаралары турында» 2008 ел, 15 декабрь, 887 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 12 март, 134 нче; 2011 ел, 13 май, 380 нче; 2012 ел, 29 февраль, 179 нчы; 2012 ел, 7 август, 671 нче; 2012 ел, 10 август, 678 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 829 нчы; 2013 ел, 12 сентябрь, 650 нче; 2014 ел, 7 июль, 458 нче; 2014 ел, 10 апрель, 236 нчы; 2015 ел, 26 июнь, 464 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә, преамбулада һәм 6 нчы пунктта «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2007/2008 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче пунктта:

икенче абзацта «2009/2010 – 2012/2013 уку елларында» сүзләрен «2009/2010 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «югары һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен – «югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары» сүзләренә, «2008/2009 – 2012/2013 уку елларында» сүзләрен «2008/2009 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче пунктта, 3 нче пунктның беренче абзацында, 4 нче пунктта «2009/2010 – 2012/2013 уку елларында» сүзләрен «2009/2010 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче пунктта «югары һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен – «югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары» сүзләренә, «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2009/2010 – 2014/2015 уку елларында Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын үтәү буенча Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары арасында үзара хезмәттәшлек итү регламентында:

исемдә һәм беренче абзацта «2009/2010 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2009/2010 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2008/2009 – 2014/2015 уку елларында Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру кысаларында республика икътисады тармаклары өчен актуаль юнәлешле проектлар темаларын билгеләү, раслау һәм беркетү буенча Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, югары һөнәри белем бирү учреждениеләре арасында үзара хезмәттәшлек итү регламентында:

исемдәге «югары һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен – «югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмалары» сүзләренә, «2008/2009 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2008/2009 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «2008/2009 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2008/2009 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче пунктта «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2007/2008 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче пунктта «югары һөнәри белем бирү учреждениесе» сүзләрен «югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

10, 11, 13 нче пунктларда тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «югары һөнәри белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «югары һөнәри белем бирүче мәгариф оешмасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2007/2008 – 2014/2015 уку елларында Россия Федерациясенең халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планын тормышка ашыру турында» 2007 ел, 27 июнь, 253 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 15 декабрь, 887 нче; 2012 ел, 5 октябрь, 829 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемдә, преамбулада, 1 нче пунктның өченче абзацында һәм 2 нче пунктта «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2007/2008 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында 2007/2008 – 2009/2010 уку елларында Идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт программасы концепциясендә:

исемдә, 1 бүлекнең дүртенче абзацында «2007/2008 – 2009/2010 уку елларында» сүзләрен «2007/2008 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

1 бүлекнең егерме бишенче абзацында «белем бирү учреждениеләрендә»

сүзләрен «белем бирү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

икенче һәм уналтынчы абзацларда тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

егерме сигезенче абзацта «В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты» сүзләрен «югары һөнәри белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлекнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад һәм сәнәгать министры тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы икътисад министры тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6 бүлекнең дүртенче, унынчы, унбишенче, унҗиденче, егерме беренче – егерме өченче абзацларында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында 2007/2008 – 2014/2015 уку елларында Россия Федерациясенең халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләү буенча дәүләт планында:

исемдә һәм икенче абзацта «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2007/2008 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

«Төп йөкләмә» бүлегендә «белем бирү учреждениеләрендә» сүзләрен «белем бирү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

«Төп чаралар» бүлегенең икенче – бишенче, җиденче – тугызынчы, унөченче – уналтынчы абзацларында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

«Финанслар белән тәэмин итү» бүлегенең беренче, дүртенче – алтынчы абзацларында, 1 нче искәрмәдә, унынчы, унберенче, ундүртенче, унтугызынчы, егерменче, егерме сигезенче, утызынчы, утыз өченче, утыз дүртенче, утыз алтынчы, утыз тугызынчы абзацларында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Россия Федерациясе халык хуҗалыгы оешмалары өчен идарә итүче кадрлар әзерләүне оештыру буенча Татарстан төбәк комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

1.1 нче пунктта «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2007/2008 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлекнең икенче, өченче, бишенче, унберенче абзацларында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү учреждениесе» сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.1 нче пунктындагы сигезенче, унөченче, унтугызынчы абзацларында тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү учреждениесе»

сүзләрен тиешле саннардагы һәм килешләрдәге «белем бирү оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлекнең 4.1 нче пунктында «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад һәм сәнәгать министры тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы икътисад министры тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 17 декабрь, б-2093 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 5 октябрь, б-1914 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктта «2007/2008 – 2014/2015 уку елларында» сүзләрен «2007/2008 – 2017/2018 уку елларында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\905.docx